**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЧУРАКАЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**

423746, Чуракай авылы, Совет ур., 69 йорт

**ЧУРАКАЕВСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

423746, село Чуракаево, ул. Советская, дом 69

КАРАР

Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Чуракай авыл җирлеге составына керүче Иске Әгъбәз авылының халык җыены нәтиҗәләре турында

26.11.2024 ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131 - ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел, № 45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2024 елның 26 ноябре 13.30 сәгатьтә Актаныш муниципаль районы Чуракай авыл җирлегенә керүче Иске Әгъбәз авылы гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнарның 2 нче җыен беркетмәсе төзелде: «2025 елда Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Иске Әгъбәз авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә ризамы, моннан тыш, 1 төркем инвалидлар һәм укуның көндезге формасы буенча укучы студентлар; Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация кысаларында мобилизацияләнгән гражданнар һәм аларның гаилә әгъзалары; Украинада махсус хәрби операция зонасында контракт буенча хәрби хезмәт үтүче хәрби хезмәткәрләрдән тыш ,аларның саны торак пунктта яшәүчеләрнең гомуми санынннан 30 проценттан артып китә алмый».

Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтү белән ризамы:

-су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне (су белән тәэмин итүне карап тоту, ремонтлау һәм төзекләндерү)тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (грейдерлау, кардан чистарту);

- торак пункт территориясен төзекләндерү (хуҗасыз территорияләрдә үлән чабу);

- урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформаторларны һәм алар астындагы башка подстанцияләрне һәм мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү, электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен

билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (урам яктыртуын карап тоту һәм ремонтлау);

-ремонт,коймалар кору, күмү урыннарын төзекләндерү (зиратларны карап тоту һәм төзекләндерү).

| | | |
|---|---|---|
| “ӘЙЕ” | "КАРШЫ" | “БИТАРАФ” |

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 178 граждан,

тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 89 граждан кертелгән.

Ачык тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

Позиция “ӘЙЕ”өчен 84 граждан тавыш бирде;

Позиция “КАРШЫ” өчен 5 граждан тавыш бирде.

Позиция “БИТАРАФ” өчен 0 граждан тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Чуракай авыл җирлегендә Иске Әгъбәз авыл гражданнар җыены булып узды.
2. Сорау буенча карарны таныргa: «2025 елда Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының Чуракай авылы территориясендә Иске Әгъбәз авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә риза, 1 төркем инвалидлардан, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан тыш, Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация кысаларында мобилизацияләнгән гражданнар һәм аларның гаилә әгъзалары; Украинада махсус хәрби операция зонасында контракт буенча хәрби хезмәт үтүче хәрби хезмәткәрләрдән тыш,аларның саны торак пунктта яшәүчеләрнең гомуми санынан 30 проценттан артып китә алмый».

Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтергә:

-су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне (су белән тәэмин итүне карап тоту, ремонтлау һәм төзекләндерү)тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (грейдерлау, кардан чистарту);

- торак пункт территориясен төзекләндерү (хуҗасыз территорияләрдә үлән чабу);

- урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформаторларны һәм алар астындагы башка подстанцияләрне һәм мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү, электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен

билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (урам яктыртуын карап тоту һәм ремонтлау);

-ремонт,коймалар кору, күмү урыннарын төзекләндерү (зиратларны карап тоту һәм төзекләндерү).

3. Әлеге карарны Чуракай авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә, Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга http://aktanysh.tatar.ru

Гражданнар җыенында рәислек итүче,

Актаныш муниципаль районы

Чуракай авыл җирлеге башлыгы Р.Р.Хайдаров